КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1495

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 27 декабрь, 1220 нче карары белән расланган 2020 – 2022 елларда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын 2020 – 2022 елларда тормышка ашыруның кыска вакытлы планын раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 27 декабрь, 1220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 апрель, 320 нче; 2020 ел, 25 июль, 624 нче; 2020 ел, 21 декабрь, 1166 нчы; 2021 ел, 18 февраль, 87 нче; 2021 ел, 18 июнь, 474 нче; 2021 ел, 26 октябрь, 1003 нче; 2021 ел, 25 декабрь, 1289 нчы; 2022 ел, 1 апрель, 301 нче, 2022 ел, 03 сентябрь, 957 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне

исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын 2020 – 2022 елларда тормышка ашыруның кыска вакытлы планына (алга таба – Кыска вакытлы план) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кыска вакытлы планның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Кыска вакытлы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасында торак фондын саклап калу, торгызу һәм аның сыйфатын күтәрү;

гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм.

Кыска вакытлы планның төп бурычлары түбәндәгеләр:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

озак вакытлы материаллар һәм ресурслар саклый торган технологияләр кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләр һәм комплекслылык куллану.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру срогы: 2020 - 2022 еллар.

2020 елда Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 6,4 кв. метр булган 1 063 күпфатирлы йортта 243 780 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш;

Кыска вакытлы планга гомуми мәйданы 946,4 мең кв.метр булган 157 күпфатирлы йортка проект документациясен эшләү кертелгән, аларны капиталь төзекләндерү 2021 елда планлаштырыла.

2021 елда Кыска вакытлы планны тормышка ашыру 5,6 кв.метр гомуми мәйданлы 959 күпфатирлы йортта 212 107 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Кыска вакытлы планга 2022 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган 15 196,2 кв.метр гомуми мәйданлы өч күпфатирлы йортка проект документациясен эшләү кертелгән.

2022 елда Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру 4,7 млн. кв. метр мәйданлы 740 күпфатирлы йортта 184 352 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Кыска вакытлы планга 2023 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган 2 652,93 кв.метр гомуми мәйданлы ике күпфатирлы йортка проект документациясен эшләү кертелгән.

Кыска вакытлы план үтәлешенең планлаштырыла торган күрсәткечләре:

тулаем Татарстан Республикасы буенча әлеге Кыска вакытлы планга 1 нче кушымтада;

Кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы муниципаль берәмлекләр киселешендә әлеге Кыска вакытлы планга 2 нче кушымтада.»;

Кыска вакытлы планның IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Кыска вакытлы план үтәлешенең планлаштырыла торган күрсәткечләре

2020 – 2022 елларда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләмнәре

| Т/с | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барысы | шул исәптән | | |
| | | | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Түбә ремонтлау, шул исәптән җилләми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп ясау, өй түбәсенә чыгу урыннарын ясау | мең кв.метр | 1 118,4 | 403,6 | 445,8 | 269,0 |
| 2. | Электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су чыгару буенча йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алмаштыру, шул исәптән торак урыннардагы җылыта торган элементларны, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазны ремонтлау яки алмаштыру, шул исәптән: | мең метр | 3 437,1 | 1 121,4 | 1 272,8 | 1 042,9 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | мең метр | 1 100,9 | 328,7 | 410,6 | 361,6 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 1 037,2 | 324,5 | 402,2 | 310,5 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | мең метр | 838,6 | 311,6 | 281,4 | 245,6 |
| 2.4. | су чыгару | мең метр | 450,9 | 154,1 | 173,7 | 123,1 |
| 2.5. | газ белән тәэмин итү | мең метр | 9,5 | 2,5 | 4,9 | 2,1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Коммуналь хезмәтләр (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) бирү өчен кирәкле ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомуми йорт) приборларын урнаштыру яки алыштыру | данә | 27 | 0 | 0 | 27 |
| 4. | Җылылык энергиясен куллану белән идарә итү узелларын һәм аны көйләү узелларын урнаштыру | данә | 61 | 53 | 8 | 0 |
| 5. | Лифтларны алыштыру | данә | 914 | 377 | 330 | 207 |
| 6. | Лифт шахталарын ремонтлау | данә | 5 | 4 | 1 | 0 |
| 7. | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау | мең кв.метр | 61,5 | 17,6 | 31,1 | 12,8 |
| 8. | Фасадны ремонтлау, халыкның аз хәрәкәтчән төркемнәре өчен күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәттән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында керү-чыгу урыннарының керү урыннары төркемнәрен пандуслар белән һәм баскыч маршларын һәр яктан култыксалар белән җиһазлау | мең кв.метр | 2 570,4 | 971,6 | 965,7 | 633,1 |
| 9. | Фасадны җылыту, халыкның аз хәрәкәтчән төркемнәре өчен күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәттән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында керү-чыгу урыннарының керү урыннары төркемнәрен пандуслар белән һәм баскыч маршларын һәр яктан култыксалар белән җиһазлау | мең кв.метр | 351,4 | 0,6 | 16,5 | 334,3 |
| 10. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | мең куб метр | 8,6 | 7,3 | 0,9 | 0,4 |
| 11. | Күпфатирлы йорттагы подъездларны ремонтлау | мең кв.метр | 280,0 | 201,4 | 50,6 | 28,0 |
| 12. | Күпфатирлы йортны янгыннан саклау системасын ремонтлау | мең кв.метр | 102,6 | 70,9 | 31,7 | 0,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 13. | Вентиляция каналларын һәм төтен чыгу юлларын ремонтлау | мең кв.метр | 5,3 | 0,6 | 2,3 | 2,4 |
| 14. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | данә | 2 759 | 1 062 | 958 | 739 |
| 15. | 2020 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күп-фатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөрес-леген тикшерү | данә | 763 | 763 | 0 | 0 |
| 16. | 2021 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күп-фатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөрес-леген тикшерү | данә | 886 | 168 | 718 | 0 |
| 17. | 2022 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күп-фатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөрес-леген тикшерү | данә | 726 | 0 | 3 | 723 |
| 18. | 2023 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күп-фатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөрес-леген тикшерү | данә | 3 | 0 | 0 | 3 |
| 19. | Җиһазлар комплексында инди-видуаль җылылык пунктларын (ИҖП) һәм булганда басымны арттыра торган насос җайлан-маларын урнаштыру | данә | 188 | 175 | 13 | 0 |

Кыска вакытлы планга кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры әлеге Кыска вакытлы планның 3 нче кушымтасында китерелде.»;

Кыска вакытлы планның V бүлегендә:

икенче абзацта «19 465 810 285,27» саннарын «19 264 856 873,65» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «3 214 435 093,29» саннарын «3 216 687 245,35» саннарына алмаштырырга;

бишенче абзацта «12 577 003 214,13» саннарын «12 373 797 650,45» саннарына алмаштырырга;

унсигезенче абзацта «6 525 124 480,46» саннарын »6 324 171 068,84» саннарына алмаштырырга;

егерменче абзацта «1 072 931 000,00» саннарын »1 075 183 152,06» саннарына алмаштырырга;

егерме беренче абзацта «4 491 761 144,95» саннарын « 4 288 555 581,27» саннарына алмаштырырга;

«2020 – 2022 елларда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 – 2022 елларда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| Т/с | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару исемлеге | Суммасы, млн.сум | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Түбә ремонтлау, шул исәптән җилләми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп ясау, өй түбәсенә чыгу урыннарын ясау | 4 195,2 | 1 346,2 | 1 558,6 | 1 290,4 |
| 2. | Электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су чыгару буенча йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алмаштыру, шул исәптән торак урыннардагы җылыта торган элементларны, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системала-рында урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазны ремонтлау яки алмаштыру, шул исәптән: | 5 432,5 | 1 637,6 | 2 065,0 | 1 729,9 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | 836,5 | 223,5 | 319,5 | 293,5 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | 2 445,8 | 747,4 | 1 009,6 | 688,8 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | 1 124,9 | 403,4 | 343,2 | 378,3 |
| 2.4. | су чыгару | 1 004,4 | 259,1 | 385,7 | 359,6 |
| 2.5. | газ белән тәэмин итү | 20,9 | 4,2 | 7,0 | 9,7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Коммуналь хезмәтләр (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) бирү өчен кирәкле ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомуми йорт) приборларын урнаштыру яки алыштыру | 5,3 | 0,0 | 0,0 | 5,3 |
| 4. | Җылылык энергиясен куллану белән идарә итү узелларын һәм аны көйләү узелларын урнаштыру | 35,8 | 27,4 | 8,4 | 0,0 |
| 5. | Лифтларны алыштыру | 2 219,0 | 820,9 | 796,1 | 602,0 |
| 6. | Лифт шахталарын ремонтлау | 0,4 | 0,3 | 0,1 | 0,0 |
| 7. | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау | 60,6 | 20,4 | 22,1 | 18,1 |
| 8. | Фасадны ремонтлау, халыкның аз хәрәкәтчән төркемнәре өчен күп-фатирлы йорттагы уртак мөлкәттән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында керү-чыгу урынна-рының керү урыннары төркемнәрен пандуслар белән һәм баскыч маршларын һәр яктан култыксалар белән җиһазлау | 4 908,3 | 1 746,9 | 1 873,9 | 1 287,5 |
| 9. | Фасадны җылыту, халыкның аз хәрәкәтчән төркемнәре өчен күп-фатирлы йорттагы уртак мөлкәттән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында керү-чыгу урын-нарының керү урыннары төркем-нәрен пандуслар белән һәм баскыч маршларын һәр яктан култыксалар белән җиһазлау | 1 100,9 | 2,7 | 53,9 | 1 044,3 |
| 10. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | 29,3 | 23,5 | 1,4 | 4,4 |
| 11. | Күпфатирлы йорттагы подъезд-ларны ремонтлау | 290,5 | 160,0 | 74,1 | 56,4 |
| 12. | Күпфатирлы йортны янгыннан саклау системасын ремонтлау | 56,5 | 23,4 | 33,1 | 0,0 |
| 13. | Вентиляция каналларын һәм төтен чыгу юлларын ремонтлау | 12,5 | 1,7 | 4,1 | 6,7 |
| 14. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 271,2 | 89,8 | 91,8 | 89,6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 15. | 2020 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 110,9 | 110,9 | 0,0 | 0,0 |
| 16. | 2021 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 188,1 | 49,9 | 138,2 | 0,0 |
| 17. | 2022 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 188,1 | 0,0 | 1,0 | 187,1 |
| 18. | 2023 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 2,5 | 0,0 | 0,0 | 2,5 |
| 19. | Җиһазлар комплексында индивидуаль җылылык пунктларын (ИҖП) һәм булганда басымны арттыра торган насос җайланмаларын урнаштыру | 157,3 | 147,1 | 10,2 | 0,0 |
| 20. | Күпфатирлы йортларда 2014 елның 1 июненә кадәр урнаштырылган (алыштырылган) коммуналь ресурсларны куллануны исәпкә алуның күмәк (гомуми йорт) приборларын урнаштыру (алыштыру) (бары торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яки күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән) | 10,2 | 4,7 | 3,1 | 2,4 |
| | Барлыгы* | 19 264,9 | 6 208,7 | 6 732,0 | 6 324,2»; |

Кыска вакытлы планга 1 нче кушымтада:
1 пунктның 1.1 пунктчасында:
4 нче графада «2 935» саннарын «2 924» саннарына алмаштырырга;
7 нче графада «753» саннарын «742» саннарына алмаштырырга;
4 пунктта:
4 нче графада «19 465,8» саннарын «19 264,9» саннарына алмаштырырга;
7 нче графада «6 525,1» саннарын «6 324,2» саннарына алмаштырырга;
4.1 пунктчада:
4 нче графада «6 888,8» саннарын «6 891,1» саннарына алмаштырырга;
7 нче графада «2 033,3» саннарын «2 035,6» саннарына алмаштырырга;
4.2 пунктчада:
4 нче графада «12 577,0» саннарын «12 373,8» саннарына алмаштырырга;
7 нче графада «4 491,8» саннарын «4 288,6» саннарына алмаштырырга;
Кыска вакытлы планга 2- 4 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин